РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТОЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Джалиля , д.19, с.Тойкино,
Азнакаевский район, 423302

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТУЙКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Җәлил ур., 19 нче йорт, Туйкә авылы,
Азнакай районы, 423302

Тел./факс(885592)-45089; E-mail: Toy.Azn@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 сентябрь 2018 ел № 14

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 2004 елның 23 мартындагы № 23-ТРЗ "Җирле референдум турында", «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар бирәм:

Җирле референдум үткәрү инициативасы:

"Сез 2019 елда Туйкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;

3) ял оештыру һәм авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

4) торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру;

5) ритуаль хезмәтләр һәм җирләү урыннарын тоту оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. 2. Әлеге карар:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил урамы, 19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Гагарин урамы, 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Камышлыкүл бистәсе, Ленин урамы, тукталыш мәйданчыгы янында;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга авылы, Сәйдәшев урамы, 19а номерлы йорт янында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

Башлык Р.Р.Закирова